**Класс**: 6

**Укытучы**: Насыбуллина Резедә Сәйрин кызы

**Программа:** Җәмгыять белеме. 6 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы /(Л.Н.Боголюбов h.б., русчадан Л.Н.Гыймадеева тәрҗемәсе)-Казан: Татар.нәшр., 2020.-160 б.:рәс.б-н.

**Тема:** Кеше һәм аның эшчәнлеге

Слайд 1

Тирә-юньдәге төрле әйберләргә игътибар ит. Син яшәгән йорт, киеп йөргән киемнәрең, укый торган китапларың, ашаган ризыкларың – боларның барысын да кешеләр җитештерә. Бу исемлекне дәвам итәргә мөмкин.

Слайд 2

Кеше тарафыннан ясалган, башкарылган, җитештерелгән һәр нәрсә аның эшчәнлек нәтиҗәсе булып тора. “Эшчәнлек” сүзе “кешенең шөгылен, аның хезмәтен” белдерә. Ул бары тик кешеләргә генә хас, аларны  хайваннардан аерып тора.

Слайд 3

Теләгән нәтиҗәләргә ирешү өчен, кеше үз ихтыярын, максатчылыгын эшкә җигәргә, авырлыкларны җиңәргә һәм үз тормышын оештыра-төзи белергә тиеш. Эшчәнлегендә кеше үзенең акылын куллана. Кытайларның “Гамәл чәчәрсең – гадәт алырсың, гадәт чәчәрсең – холык алырсың, холык чәчәрсең – язмыш алырсың” гыйбарәсе юкка гына әйтелмәгән.

Слайд 4

Кеше эшчәнлектә, гамәлләрдә, мөнәсәбәтләрдә ачылып кына калмый, ә аларда формалаша да. Борыңгы грек философы Демокрит: “Тумыштан түгел, ә күбесенчә күнекмәләрдән яхшы кешегә әвереләсең”-, дип раслый. Мәсәлән, гаделлек гадел гамәлләр кылганда гына ачыла, ә бу гамәлләр, кеше тормышында очраклы күренешләр булмыйча, гадәткә әйләнсә генә, шәхеснең сыйфаты булып ныгый.

Слайд 5

Кеше ни белән генә шөгыльләнмәсен, аннан иң элек тиешле белем һәм күнекмәләр таләп итә. Шуңа күрә уку, белем алу -һәртөрле максатка ирешүдә беренче адым ул.

Слайд 6

Эш инде ахырына кадәр җиткерелгән икән, аның нәтиҗәләрен бәяләү, киләчәктә кабатламас өчен, нинди хаталар җибәрелүен ачыклау мөһим

(укытучы теге яки бу теманың укучылар тарафыннан ни өчен яхшы үзләштерелмәве турында уйлана; табиб теге яки бу авыру кешегә ни өчен ярдәм итеп булмавын уйлый; менеджер исә билгеләнгән проектның көтелгән табышны китермәвен ачыклый).

Слайд 7

Кеше күптөрле эшчәнлек алып бара. Хезмәт кенә түгел, уен, уку да эшчәнлек була. Күп кенә галимнәр аралашуны да мөһим эшчәнлек төре дип саныйлар. Аннан башка үзеңне тулысынча кеше буларак таныту бик авыр. Аралашу турында җентекләп сөйләү бераз соңрак булыр.

Слайд 8

Уенны уку һәм хезмәт белән янәшә кую сезне һич гаҗәпләндермәсен. Уен-җитди эш, ул балаларга бик күп яңа нәрсәләр белергә, олы тормышка әзерләнергә булыша. Яшьтәшләр белән аралашканда, характер формалаша, сөйләм үсә. Яшьтәшләр белән араларашу кешегә шатлык китерә, аны бәхетле итә. Уйнаганда, билгеле бер кагыйдәләр үтәлергә  тиеш. Бала үз теләкләрен башка уенчылар теләге белән генә түгел, ә уен таләпләре белән дә яраштырырга өйрәнә.

Слайд 9

Мәктәпкә укырга бару- кеше гомеренең җитди үзгәреш вакыты ул.Уку, уеннан аермалы буларак, баланың үтәлергә тиешле шөгыленә әйләнә. Аның яңа хокуклары һәм йөкләмәләре барлыкка килә. Укучы белем алуга билгеләнгән вакытны үз белемнәрен баету өчен кулланырга, системалы төстә дәресләргә әзерләнергә, укытучыларны игътибар белән тыңларга, барлык күрсәтмәләрен үтәргә тиеш.

Слайд 10

Әлеге таләпләр укучыны белем һәм күнекмәләр алуга гына этәреп калмый, аның кешелек сыйфатлары үсешенә, эшчәнлек уңышына да булышлык итә.

**Практик өлеш:**

Слайд 11

Балалар, экрандагы сорауларга җавап бирегез. Үзегезнең җавапларыгызны, дөрес җаваплар белән чагыштырыгыз.

1) “Эшчәнлек” сүзенең  мәгънәсен аңлат.
2) Ни өчен кеше генә эшчәнлек белән шөгыльләнә ала дип саныйлар?
3) Кайсыларын төп эшчәнлек төрләре диләр? Ни өчен?
4) Кешенең эшчәнлеге һәм сыйфатлары арасында бәйләнеш нинди?
5) Уңышлы эшчәнлек шарты нәрсә ул?

6) “Үземнең уку эшчәнлегемне ничек камилләштерергә” проектын башкар.
   Җаваплар:
   1) “Эшчәнлек” сүзе “кешенең шөгылен, аның хезмәтен” белдерә.
   2) Эшчәнлек кешеләргә генә хас, аларны хайваннардан аерып тора.
   3) Кеше күптөрле эшчәнлек алып бара. Хезмәт кенә түгел, **уен, уку** да эшчәнлек була. Күп кенә галимнәр **аралашуны** да мөһим эшчәнлек төре дип саныйлар.
   4) Кеше эшчәнлектә, гамәлләрдә, мөнәсәбәтләрдә ачылып кына калмый, ә аларда формалаша да. Борыңгы грек философы Демокрит: “Тумыштан түгел, ә күбесенчә күнекмәләрдән яхшы кешегә әвереләсең”, дип раслый. Мәсәлән, гаделлек гадел гамәлләр кылганда гына ачыла, ә бу гамәлләр, кеше тормышында очраклы күренешләр булмыйча, гадәткә әйләнсә генә, шәхеснең сыйфаты булып ныгый.
   5) Билгеләнгән вакытны үз белемнәрен баету өчен кулланырга. Системалы төстә дәресләргә әзерләнергә.
      Укытучыларны игътибар белән тыңларга.

**Йомгаклау**